Республика Татарстан

САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» февраль 2020 ел № 21

Саба шәһәр башкарма комитетының 28.04.2018 елгы №45 карары белән расланган "Муниципаль милек булып торучы җирләрне торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен җир биләмәләрен арендалауга килешү хокукын төзү һәм сату буенча аукцион оештыру һәм үткәрү" муниципаль хезмәте күрсәтү буенча Административ регламент”ына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 19.07.2018 ел, №204-ФЗ Федераль Законына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба шәһәр башкарма комитетының 28.04.2018 елгы №45 карары белән расланган "Муниципаль милек булып торучы җирләрне торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен җир биләмәләрен арендалауга килешү хокукын төзү һәм сату буенча аукцион оештыру һәм үткәрү" муниципаль хезмәте күрсәтү буенча Административ регламент”ына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.13нче пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорауларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, шул исәптән инвалидларга социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гыйлманов